КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 24 апрель г.Казань № 339

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме күрсәтү чаралары турында» 2018 ел, 17 гыйнвар, 17 нче карары белән расланган Авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләргә культуртехника, урман агромелиорациясе һәм гидромелиорация чараларын үткәрүгә бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджет белән бергә финанслана торган субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме күрсәтү чаралары турында» 2018 ел, 17 гыйнвар, 17 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 5 март, 138 нче; 2018 ел, 2 апрель, 200 нче; 2018 ел, 5 июнь, 425 нче; 2018 ел, 4 июль, 550 нче; 2018 ел, 8 декабрь, 1090 нчы; 2019 ел, 25 гыйнвар, 41 нче; 2019 ел, 28 февраль, 148 нче; 2019 ел, 26 апрель, 347 нче; 2019 ел, 29 апрель, 350 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Федераль бюджеттан финансланучы крестьян (фермер) хуҗалыкларын төзү һәм үстерү проектларын гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан «Агростартап» грантларын бирү тәртибе;

«Агымдагы финанс елында федераль бюджеттан финансланучы аерым чыгымнарның бер өлешен каплау өчен авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибе;

2 пунктта «кулланучылар кооперативларының» сүзләреннән соң «, «Агростартап» крестьян (фермер) хуҗалыкларын булдыру һәм үстерү проектларын гамәлгә ашыруга» сүзләрен өстәргә;

әлеге карар белән расланган Авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләргә, шулай ук фәнни оешмаларга, һөнәри белем бирү оешмаларына, югары белем бирүче мәгариф оешмаларына үсемлекчелек өлкәсендә, орлык бәрәңге, ачык грунт яшелчәләре һәм озын сүсле җитен җитештерүне үстерү өлкәсендә файдалану юнәлешләре мөстәкыйль билгеләнә торган ярдәм күрсәтүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджет белән бергә финанслана торган субсидияләр бирү тәртибендә:

6 пунктта:

беренче абзацта «орлык бәрәңге һәм (яки)» сүзләрен төшереп калдырырга;

дүртенче абзацта «орлык бәрәңге һәм (яки)» сүзләрен төшереп калдырырга;

бишенче абзацта «орлык бәрәңге һәм (яки)» сүзләрен төшереп калдырырга;

алтынчы абзацта «орлык бәрәңге һәм (яки)» сүзләрен төшереп калдырырга;

түбәндәге эчтәлекле $6^1$ пункт өстәргә:

«$6^1$. Орлык бәрәңгесен җитештерүне үстерү өлкәсендә ярдәм алучыга бирелә торган субсидия күләме түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$W = \frac{Z \times 15}{100},$$

монда:

W – орлык бәрәңге җитештерүне үстерү өлкәсендә ярдәм алучыга бирелә торган сумнарда субсидия күләме, сум;

Z – хисап финанс елына орлык бәрәңге җитештерүгә чыгымнар, сум.»;

10 пунктта:

«а» пунктчасын төшереп калдырырга;

«б» пунктчаның беренче абзацын төшереп калдырырга;

түбәндәге эчтәлекле $10^1$ пункт өстәргә:

«$10^1$. Әлеге Тәртипнең $6^1$ пунктында күрсәтелгән субсидияләрне алу өчен алар Идарәгә өстәмә рәвештә тапшыралар:

Татарстан Республикасы буенча «Россия авыл хуҗалыгы үзәге» Федераль дәүләт бюджет учреждениесенең Татарстан Республикасы буенча филиалы тарафыннан расланган финанс хисабы елының чәчүлекләренең сорт сыйфатларын апробацияләү яисә теркәү акты;

хисап финанс елына үсемлекчелек продукциясен җитештерү, чыгымнар, үзкыйммәте һәм сату турында хисап күчермәсе һәм (яки) финанс хисап елы өчен крестьян (фермер) хуҗалыкларының җитештерү эшчәнлеге турында мәгълүмат;

белешмә-Министрлык тарафыннан расланган форма буенча тиешле субсидияләр турында исәп-хисап.

Тапшырылган документларның күчермәләре алучылар тарафыннан раслана.»;

12 пунктның икенче абзацында «БАРС. Авыл хуҗалыгы. Субсидия бирү» гаризаларын теркәү электрон системасына кергән» сүзләрен «Татарстан

Республикасы агросәнәгать комплексы» мәгълүмат системасында» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган  Авыл  хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләргә затлы орлыкчылыкны үстерү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджет белән бергә финанслана торган субсидияләр бирү тәртибенең 8 пунктындагы икенче абзацында «БАРС. Авыл хуҗалыгы. Субсидия бирү» гаризаларын теркәү электрон системасына кергән» сүзләрен «Татарстан Республикасы агросәнәгать комплексы» мәгълүмат системасында» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган  Авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләргә күпьеллык үсентеләр үстерүдә булышлык күрсәтү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджет белән бергә финанслана торган субсидияләр бирү тәртибенең 8 пунктындагы икенче абзацында «БАРС. Авыл хуҗалыгы. Субсидия бирү» гаризаларын теркәү электрон системасына кергән» сүзләрен «Татарстан Республикасы агросәнәгать комплексы» мәгълүмат системасында» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган  Авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә, шулай ук фәнни оешмаларга, һөнәри белем бирү оешмаларына, югары белем бирүче мәгариф оешмаларына Татарстан Республикасы бюджетыннан сөтчелек терлекчелеге продуктивлылыгын арттыруга юнәлдерелгән һәм федераль бюджеттан финанслаша торган субсидияләр бирү тәртибенең 9 пунктындагы икенче абзацында «БАРС. Авыл хуҗалыгы. Субсидия бирү» гаризаларын теркәү электрон системасына кергән» сүзләрен «Татарстан Республикасы агросәнәгать комплексы» мәгълүмат системасында» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган  Авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләргә шулай ук фәнни оешмаларга, һөнәри белем бирү оешмаларына, югары белем бирүче мәгариф оешмаларына нәселле терлекчелеккә булышлык күрсәтү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджет белән бергә финанслана торган субсидияләр бирү тәртибенең 12 пунктындагы икенче абзацында «БАРС. Авыл хуҗалыгы. Субсидия бирү» гаризаларын теркәү электрон системасына кергән» сүзләрен «Татарстан Республикасы агросәнәгать комплексы» мәгълүмат системасында» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләргә сарык һәм кәҗәләрнең ана башларын саклау һәм үрчетү чыгымнарының бер өлешен каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджет белән бергә финанслана торган субсидияләр бирү тәртибенең 7 пунктындагы икенче абзацында «БАРС. Авыл хуҗалыгы. Субсидия бирү» гаризаларын теркәү электрон системасына кергән» сүзләрен «Татарстан Республикасы агросәнәгать комплексы» мәгълүмат системасында» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләргә агросәнәгать комплексы объектларын төзү һәм (яки) модернизацияләүгә турыдан-туры тотылган чыгымнарның бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджет белән бергә финанслана торган субсидияләр бирү тәртибенең 8 пунктындагы икенче абзацында «БАРС. Авыл хуҗалыгы. Субсидия бирү» гаризаларын теркәү электрон системасына кергән» сүзләрен «Татарстан

Республикасы агросәнәгать комплексы» мәгълүмат системасында» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләргә культуртехника, урман агромелиорациясе һәм гидромелиорация чараларын үткәрүгә бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджет белән бергә финанслана торган субсидияләр бирү тәртибенең 11 пунктындагы икенче абзацында «БАРС. Авыл хуҗалыгы. Субсидия бирү» гаризаларын теркәү электрон системасына кергән» сүзләрен«Татарстан Республикасы агросәнәгать комплексы» мәгълүмат системасында» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Авыл хуҗалыгы иминиятләве шартнамәләре буенча иминият премияләрен түләү өчен чыгымнарның бер өлешен каплауга авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләргә Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджет белән бергә финанслана торган субсидияләр бирү тәртибенең 10 пунктындагы икенче абзацында «БАРС. Авыл хуҗалыгы. Субсидия бирү» гаризаларын теркәү электрон системасына кергән» сүзләрен «Татарстан Республикасы агросәнәгать комплексы» мәгълүмат системасында» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләргә үсемлекчелек һәм терлекчелек тармакларын үстерүнең максатчан күрсәткечләренә ирешүгә булышлык күрсәтү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджет белән бергә финанслана торган субсидияләр бирү тәртибенең 7 пунктындагы икенче абзацында «БАРС. Авыл хуҗалыгы. Субсидия бирү» гаризаларын теркәү электрон системасына кергән» сүзләрен «Татарстан Республикасы агросәнәгать комплексы» мәгълүмат системасында» сүзләренә алмаштырырга;

бу Impарга Федераль бюджеттан финансланучы крестьян (фермер) хуҗалыкларын төзү һәм үстерү проектларын гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы бюджетыннан «Агростартап» грантлар бирү тәртибен, Агымдагы финанс елында федераль бюджеттан финансланучы аерым чыгымнарның бер өлешен каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларына субсидияләр бирү тәртибен өстәргә (карарга теркәлә).

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы Р.К.Нигъмәтуллин